| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВАРЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

2026 ел, 19 июнь № 67

Казан шәһәре

Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 317 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.

2. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 25 маендагы 126 номерлы боерыгын;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 24 апрелендәге 27 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләрнең 2 пунктын;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 25 маендагы 126 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 февралендәге 12 номерлы боерыгын

3. Автомобиль юллары идарәсенең автомобиль юллары бүлеге җитәкчесенә

дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Ә.Фәйзуллинга йөкләргә.

Министр Ф.М.Хәнифов

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының
___________________ № _____
боерыгы белән расланды

Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Регламент) региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук Татарстан Республикасының ике һәм аннан күбрәк муниципаль берәмлеге (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территориясендә төзелә яки реконструкцияләнә торган шәхси автомобиль юлларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) 1 статьясындагы 16 пункты нигезендә төзүче функцияләрен башкаручы юридик яки физик затлар, шул исәптән төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган үз функцияләрен тапшырган техник заказчылар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

2.1.1. Объектны файдалануга керту өчен рөхсәт бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы

министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт (Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны төзүгә рөхсәт рәвешен һәм объектны файдалануга кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында» 2022 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы боерыгы белән расланган үрнәк буенча);

2) Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының кертелгән үзгәрешләре белән бергә «Объектны төзүгә рөхсәт рәвешен һәм объектны файдалануга кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында» 2022 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы боерыгы белән расланган рәвеш буенча объектны файдалануга кертүгә рөхсәт;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язуын рәсмиләштерү каралмаган.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче түбәндәгечә ала:

мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап Бердәм портал яисә Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, Бердәм порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында яисә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында электрон документ рәвешендә (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы);

Министрлыкта электрон документ яисә электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе рәвешендә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты.

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты, әгәр гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән бирелгән булса, гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып биш эш көне тәшкил итә.

2.4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда яисә Республика порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага Бердәм порталның яисә Республика порталының шәхси кабинетында чагылдырыла торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән алып биш эш көне тәшкил итә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

2.5.1. Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

2.6.1. Гаризаны биргәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәсен теркәүгә алу чоры.

2.7.1. Бердәм портал, Республика порталы аша эш көннәрендә җибәрелгән гариза Министрлык тарафыннан кабул ителгән көнне үк теркәлә.

Гаризаны Бердәм портал яисә Республика порталы аша җибәргәндә, гариза кергән көнне мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында гаризаны җибәрү фактын раслый торган, гаризаны теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәр ала.

2.7.2. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне теркәлә.

2.7.3. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырыла.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.9.1. Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырыла.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасы» мәгълүмат системасы

2.10.3. «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

2.10.4. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан яки Республика порталыннан файдаланып

тапшырырга;

в) электрон формада бирелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм порталдан яки Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал яки Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.10.5. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда яки Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара эшчәнлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында расланган исәп язмасы ярдәмендә Бердәм порталда яисә Республика порталында авторизацияләнә, дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны, интерактив рәвештән файдаланып, электрон рәвештә тутыра.

2.10.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы хезмәткәре язма мөрәҗәгать буенча мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен һәм әлеге Регламентта күрсәтелгән сорауларны җентекләп язма рәвештә аңлата һәм законнарда билгеләнгән срок дәвамында җавапны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.11.1. Әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, түбәндәгечә бүленешләр белән:

а) мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшыра торган документлар;

б) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган документлар.

2.11.2. Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү турындагы гариза рәвеше шушы Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

Объектны файдалануга кертүгә элегрәк бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза рәвеше шушы Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы

исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) гариза дәүләт хезмәтен күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына бирелгән;

2) гариза рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча яисә дөрес тутырмау;

3) тапшырылган документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта);

4) тапшырылган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган текстны чистарту һәм төзәтүләр булса;

5) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

6) гариза һәм документларны «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар исемлегеннән мөрәҗәгать итүче үзе тапшыра торган документларның булмавы;

2) капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү буенча төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын тапшыру датасына билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки, линияле объектны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (территорияне планлаштыру буенча документация әзерләүне таләп итми торган линияле объектны төзү, реконструкцияләү очракларыннан тыш) таләпләренә, урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве;

3) капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын, линия объекты озынлыгын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш;

4) төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары параметрларына туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын, линия объекты озынлыгын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^2$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш;

5) капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирелгән датага җир законнары һәм

Россия Федерациясенең башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә җавап бирмәве, күрсәтелгән чикләмәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7 өлешендәге 9 пунктында каралган очракларда кабул ителгән территориядән файдалану буенча махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки әлеге зонаны үзгәртү турында карарда каралган һәм урнаштырылуына бәйле рәвештә территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләнгән яки үзгәртелгән төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объекты файдалануга кертелмәгән очраклардан тыш.

Линия объекты булмаган капиталь төзелеш объектының техник планда күрсәтелгән мәйданы турындагы күрсәткечләрнең проект документациясендә һәм (яисә) төзелешкә бирелгән рөхсәттә күрсәтелгән мондый капиталь төзелеш объектының мәйданы турындагы күрсәткечләргә карата биш проценттан да артыграк булмаган аермасы техник планда күрсәтелгән катлар, биналар (булган очракта) һәм машина урыннары (булган очракта) саны проект документациясенә һәм (яисә) төзелешкә рөхсәткә туры килгән очракта объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. Линия объектының техник планда күрсәтелгән озынлыгы турындагы күрсәткечләрнең проект документациясендә һәм (яисә) төзелешкә рөхсәттә күрсәтелгән күрсәткечләргә карата иң күбе биш процентка аермасы объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) үткәрелә торган административ процедураны, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедураны, мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике

һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

1) мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гарызнамәне, документларны һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.3. Дәүләт хезмәте алгарышлы (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гарызнамәне карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү түбәндәге ысулларның берсе белән гамәлгә ашырыла:

шәхсән (Министрлыкта булганда);

мәгълүматны мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында Бердәм порталда яисә Республика порталында урнаштыру юлы белән.

Объектны файдалануга кертүгә
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтү административ
регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен түбәндәге билгеләр һәм кыскартылулар кулланыла:

1. Регламент – Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты.

2. Дәүләт хезмәте – объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте.

3. Мөрәҗәгать итүче – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 1 статьясындагы 16 пункты нигезендә төзүче функцияләрен башкаручы юридик яки физик затлар, шул исәптән төзүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда каралган үз функцияләрен тапшырган техник заказчылар.

4. Мөрәҗәгать итүченең вәкиле – мөрәҗәгать итүче тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар.

5. Бердәм портал – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://www.gosuslugi.ru/).

6. Министрлык – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы.

7. Республика порталы – «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (https://uslugi.tatarstan.ru/).

8. РФ Шәһәр төзелеше кодексы – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы.

9. 210-ФЗ номерлы федераль закон – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон.

Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны төзүгә рөхсәт рәвешен һәм объектны файдалануга кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында» 2022 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы боерыгы белән расланган рәвеш буенча объектны файдалануга кертүгә рөхсәт | Физик зат | 1А |
| 2. | | Юридик зат | 2А |
| 3. | | Мөрәҗәгать итүченең вәкиле | 3А |
| 4. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының кертелгән үзгәрешләре белән бергә «Объектны төзүгә рөхсәт рәвешен һәм объектны файдалануга кертүгә рөхсәт рәвешен раслау турында» 2022 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы боерыгы белән расланган рәвеш буенча объектны файдалануга кертүгә рөхсәт | Физик зат | 1Б |
| 5. | | Юридик зат | 2Б |
| 6. | | Мөрәҗәгать итүченең вәкиле | 3Б |

Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләрен, төркемнән документлар санын расшифровкалау | Мөрәҗәгать итүченең идентификаторы | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| 1. Мөрәҗәгать итүче үзе тапшыра торган документлар | | | |
| 1.1. | шәхесне таныклаучы документ | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.2. | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | 3А, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.3. | Объектны файдалануга кертүгә әлеге Регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән рәвеш буенча рөхсәт бирү турында гариза | 1А, 2А, 3А | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.4. | Төзелешкә рөхсәт | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.5. | Элек бирелгән объектны файдалануга кертүгә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасында китерелгән рәвеш буенча гариза | 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.6. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | теркәлмәгән җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турындагы килешү, гавами сервитут билгеләү турындагы карарның реквизитлары | | Республика порталы |
| 1.7. | Төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик ялгау) турында акт (мондый тоташтыру (технологик ялгау) проект документларында каралган очракта) | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.8. | Җир кишәрлеге чикләрендә төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының урнашуын, инженер-техник тәэминат челтәрләренең урнашуын һәм җир кишәрлеген оештыру планын чагылдыра торган һәм төзелешне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы зат һәм төзүче оешма тарафыннан яки, төзелешне, үзгәртеп коруны подряд килешүе нигезендә гамәлгә ашырган очракта, техник заказчы тарафыннан) имзаланган схема, линияле объектны төзү, үзгәртеп кору очракларыннан тыш | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.9. | Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | документлары таләпләренә (эш документларына кертелгән һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 1[3] өлеше нигезендә мондый проект документларының өлеше булып торган үзгәрешләрне дә исәпкә алып) туры килүе турында бәяләмә реквизитлары (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырылу каралган очракта), федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган бәяләмә реквизитлары | | |
| 1.10. | «Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты реквизитлары, әлеге объектка реставрация, консервация уздырганда, аны ремонтлаганда һәм заманча файдалану өчен яраклаштырган очракта | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 1.11. | «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әзерләнгән капиталь төзелеш объектының техник планы (капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүдән тыш, аңа карата «Күчемсез милек объектларының аерым төрләренә хокукларны рәсмиләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр дәүләт кадастр исәп-хисабы һәм (яки) хокукларны дәүләт теркәве гамәлгә ашырылмый) | | |
| 1.12. | «Россия Федерациясендә виноградчылык һәм шәраб ясау турында» 2019 елның 27 декабрендәге 468-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясында каралган төзелеш шартларына төзелеш авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләреннән, һәм авыл хуҗалыгыннан файдалану зоналары составындагы җир кишәрлекләрендә, шул исәптән милек хокукында, аренда хокукында яисә башка законлы нигездә шәраб җитештерү хуҗалыкларына яисә виноградчылык хуҗалыкларына караган торак пунктлардагы авыл хуҗалыгы җирләре | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 2. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш | | | |
| 2.1. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән җир кишәрлегенә | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хокук билгеләүче документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турындагы килешү, гавами сервитут билгеләү турында карар | | порталы |
| 2.2. | Төзелешкә рөхсәт | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 2.3. | Дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән проект документлары таләпләренә (эш документларына кертелгән һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының $1^3$ өлеше нигезендә мондый проект документларының өлеше булып торган үзгәрешләрне дә исәпкә алып) туры килүе турында бәяләмә (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 1 өлеше нигезендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырылу каралган очракта), федераль дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының РФ Шәһәр төзелеше кодексының 54 статьясының 5 өлешендә каралган очракларда бирелә торган бәяләмә | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика порталы |
| 2.4. | «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б | Министрлык, Бердәм портал, Республика |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәдәни мирас объектларын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты, әлеге объектка реставрация, консервация уздырганда, аны ремонтлаганда һәм заманча файдалану өчен яраклаштырган очракта | | порталы |

Объектны файдалануга кертүгә
рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтү административ
регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Нигезләр исемлеге | Мөрәҗәгать итүченең идентификаторы |
|---|---|---|
| 1. Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1.1. | гариза дәүләт хезмәтен күрсәтүгә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына бирелгән | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 1.2. | гариза рәвешендә, шул исәптән Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның интерактив рәвешендә кырларны тулысынча яисә дөрес тутырмау | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 1.3. | тапшырылган документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, – дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта) | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 1.4. | тапшырылган документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган текстны чистарту һәм төзәтүләр булса | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 1.5. | электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 1.6. | гариза һәм документларны «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру | |
| 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган | | |
| 3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 3.1. | әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән документлар исемлегеннән мөрәҗәгать итүче үзе тапшыра торган документларның булмавы | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 3.2. | капиталь төзелеш объектының капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору буенча төзелешкә рөхсәт алу өчен җир кишәрлегенең шәһәр төзү планын тапшыру датасына билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки, линияле объектны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау очрагында, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты (территорияне планлаштыру буенча документация әзерләүне таләп итми торган линияле объектны төзү, үзгәртеп кору очракларыннан тыш) таләпләренә, урнаштырылуы өчен җир кишәрлеген оештыру таләп ителми торган линияле объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 3.3. | капиталь төзелеш объектының төзелешкә рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын, линия объекты озынлыгын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^{2}$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 3.4. | төзелгән, үзгәртеп корылган капиталь төзелеш объектының проект документлары параметрларына туры килмәве, капиталь төзелеш объектының мәйданын, линия объекты озынлыгын РФ Шәһәр төзелеше кодексының 55 статьясындагы $6^{2}$ өлеше нигезендә үзгәртү очракларыннан тыш | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |
| 3.5. | капиталь төзелеш объектының җир кишәрлегеннән рөхсәтле файдалануга һәм (яки) объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирелгән датага җир законнары һәм Россия Федерациясенең башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләмәләргә җавап бирмәве, күрсәтелгән | 1А, 2А, 3А, 1Б, 2Б, 3Б |

| | | |
|---|---|---|
| | чикләмәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7 өлешендәге 9 пунктында каралган очракларда кабул ителгән территориядән файдалану буенча махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки әлеге зонаны үзгәртү турында карарда каралган һәм урнаштырылуына бәйле рәвештә территориядән файдалануда махсус шартлары булган зона билгеләнгән яки үзгәртелгән төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объекты файдалануга кертелмәгән очраклардан тыш | |

Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 5 нче кушымта

Рәвеше

кемгә: Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына
кемнән:________________________________________
(төзелешне, капиталь ремонтны яки реконструкцияне
________________________________________
гамәлгә ашыручы - төзүче оешма исеме; ИНН;
юридик һәм почта адреслары; электрон почта адресы;
Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);
________________________________________
телефон; банк реквизитлары
________________________________________
(банк атамасы, и-х/с, к/с, БИК)

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза

Автомобиль юлын файдалануга кертүгә рөхсәт бирүегез турында үтенәм
____________________________________________________________________________________
(атамасы)
түбәндәге адрестагы җир кишәрлегендә: ____________________________________
(шәһәр, район, урам, участок номеры)
____________________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________________

Төзелеш (реконструкция) төзелешкә бирелгән _______ елның «___» ________________ № ________ рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырылды.
Җирдән файдалану хокукы беркетелгән ________________________________________
(документ исеме)
________________________________________ ____ елның «____»_________ № __________.

Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:

Төзелешне (реконструкцияне) финанслау гамәлгә ашырылды: ________________________________
________________________________________________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)
Эшләр 20___ елның «___»______________ № _____ килешү нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән алып барылды
____________________________________________________________________________________
(оешманың атамасы, ИНН, юрилик һәм почта адреслары, җитәкченең ФИА,
____________________________________________________________________________________
телефон номеры, электрон почта адресы,
____________________________________________________________________________________
банк реквизитлары (банк аталышы, и-х/с, к/с, БИК)
Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы беркетелгән_________________________________
____________________________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың атамасы)
____________________________________________________________________________________

«____»___________________ ел, №____________________
Эшләрне башкаручы итеп «___»___________ ел,
№____________ боерык нигезендә ________________________________ билгеләнгән.

(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, ата исеме)
______________________ махсус белеме һәм эш стажы бар
(югары, урта)
төзелештә ел
Төзелеш контроле «___»________ ел, № _____________ шартнамә нигезендә
________________________________________________ тарафыннан башкарылды.
____________________________________________________________________________________
(оешманың атамасы, ИНН, юрилик һәм почта адреслары, җитәкченең ФИА,
____________________________________________________________________________________
телефоны, банк реквизитлары (банк атамасы, исәп-хисап счеты, к/счеты, БИК)

____________________________________________________________________________________

заказчы (төзүче) функцияләрен үтәү хокукы беркетелгән_______________________________________________________
________________________________________________________________________________________________________________
(документның һәм аны биргән оешманың исеме)
№ ____________ «____»___________________ ел.
Төзелгән (реконструкцияләнә торган) автомобиль юлына милек хокукын дәүләт теркәвенә алуга ризалык белдерәм. (_____________________________________________________________________________________________)
(хокукларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашырган өчен дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүмат)
Әлеге гаризада китерелгән белешмәләргә бәйле барлык үзгәрешләр турында _______________________________________
(вәкаләтле орган атамасы)
________________________________________________________________________________________________________________
хәбәр итәргә сүз бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| ________________________ | ____________________ | __________________________________ |
| (вазыйфа) | (имза) | (Фамилия, исем, ата исеме) |

«___»______________20_____ ел.

Мөһер урыны (булган очракта)

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 6 нчы кушымта

Рәвеше

кемгә: Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына
кемнән:_______________________________________
(төзелешне, капиталь ремонтны яки реконструкцияне гамәлгә ашырырга планлаштыручы төзүче оешма исеме;
_______________________________________
ИНН;
юридик һәм почта адреслары;
Җитәкченең фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта);
_______________________________________
телефон; банк реквизитлары
(банк атамасы, и-х/с, к/с, БИК)

Объектны файдалануга кертүгә элек бирелгән рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза

Капиталь төзелеш объектын файдалануга кертүгә элек бирелгән 20___ елның «____»_____________ рөхсәткә үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм.
№ ____________________ ____________________________________________________________________
(объектның атамасы)
түбәндәге адрестагы җир кишәрлегендә: ______________________________________________________
(шәһәр, район, урам, кишәрлек номеры)
Төзелеш (реконструкция) түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырылды
____________________________________________________ _____ елның «____»_________ № _______
(документ исеме)
Җирдән файдалану хокукы беркетелгән ____________________________________________________________
____________________________________________________ _____ елның «____»_________ № _______
(документ исеме)
Өстәмә рәвештә мәгълүмат җиткерәбез:
Капиталь төзелеш объектын төзүне (реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны) төзүче тарафыннан финанслау гамәлгә ашырылды ____________________________________
(банк реквизитлары һәм счет номеры)
Эшләр 20___ елның «___»______________ № _____ килешү нигезендә подряд (хуҗалык) ысулы белән алып барылды.
________________________________________________________________________________________________
(оешманың аталышы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкченең телефон номеры, банк реквизитлары
________________________________________________________________________________________________
(банк атамасы, и-х/с, к/с, БИК)
Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы беркетелгән ____________________________________________
________________________________________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән вәкаләтле оешманың атамасы)
«____»____________________ ел, №_______________________
Эшләрне башкаручы итеп «___»___________ ел,
№ _________ боерык нигезендә ___________________________________ билгеләнде, ул ________________________
(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме) (югары, урта)
махсус белемле һәм төзелештә эш стажы _____ ел.
Төзелеш контроле «___»________ ел, № _____________ шартнамә нигезендә
башкарылды ______________________________________________________________
(оешманың атамасы, ИНН, юридик һәм почта адреслары, җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта),
________________________________________________________________________________________________
телефоны, банк реквизитлары (банк атамасы, исәп-хисап счеты, к/счеты, БИК)
заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы беркетелгән __________________________________________
________________________________________________________________________________________________
(документ исеме һәм аны биргән оешма атамасы)
____________________________________________________ _____ елның «____»_________ № _________
Бу гаризада бәян ителгәннәргә бәйле барлык үзгәрешләр турында

_________________________________ хәбәр итәргә вәгъдә бирәм
(вәкаләтле орган атамасы)

______________________ ________________ ____________________________________________
(вазыйфа) (имза) (ФИА (соңгысы – булган очракта))

«_» _____20_ ел. Мөһер урыны (булган очракта)